ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.02.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№242**

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен Зеленодольск муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының 2021 елның беренче кварталына нормативын билгеләү турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2020 елның 24 декабрендәге «2021 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының нормативы һәм 2021 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 852/пр номерлы Боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының 2021 елның беренче кварталына торак сатып алуга яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен нормативны 53 919 (илле өч мең тугыз йөз унтугыз) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев